*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 44**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) колын**
   ә) сөт
   б) буран
   в) укучы

2. Басымы дөрес күрсәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ба-ра-сыз-мы′
   ә) ба-ра-сы′з-мы
   **б) ба-ра′-сыз-мы**
   в) ба′-ра-сыз-мы

3. Диалекталь сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) җиләк
   ә) архаизм
   б) хоккей
   **в) әпәй**

4. Ясалма нигезле сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) ашадылар**
   ә) сөлге
   б) киттек
   в) йөгереп

5. Вакыт рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кыш
   **ә) язын**
   б) күп
   в) шактый

6. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кайда

**ә) кемдер**
б) һәрнәрсә
в) һичнәрсә

7. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Комнан аркан ишеп, күлне күккә асып булмый.* (Мәкаль)
а) аркан
ә) ишеп
**б) асып булмый**
в) булмый

8. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кеше яраткан эшен яхшы эшли.* (Мәкаль)
**а) гади җөмлә**
ә) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
в) иярченле кушма җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Үпкәдән килә торган һава агымының, тоткарлыкка очрамыйча, тавыш ярдәмендә генә ясалган сөйләм авазлары **сузык** авазлар дип аталалар. Билгеле бер грамматик формада гына омоним булган сүзләр **омоформа** дип атала. **Ясагыч** кушымчалар сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртәләр һәм яңа сүз ясыйлар. Предметның кемнеке икәнен, кайсы затка караганын белдерә торган алмашлыклар **тартым** алмашлыклары дип атала. Зат-сан белән төрләнми торган фигыльләр **затланышсыз** фигыльләр дип атала. **Урын** хәле беркайчан да аерымланмый.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**
*паутина – пәрәвез* *экономика – икътисад*
*культура – сәнгать* *гостиница – кунакханә*
*политика – сәясәт* *желание – теләк*

2. “Алтын көз” дигән темага 12 җөмләдән торган инша языгыз. **(16 балл)**